ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.03.2020 Олы Кайбыч ав. № 161

«Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм алу» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына балаларны исәпкә алу» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 16 гыйнварындагы 23/20 номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 30 апрелендәге 222 номерлы карары белән расланган «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм алу» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

I бүлекнең 1.2 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Бер гаиләдә яшәүче һәм гомуми яшәү урыны булган балалар үзләренең бертуган абыйлары һәм (яисә) апалары белем ала торган оешмада мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программалары буенча укырга өстенлекле кабул итү хокукына ия»;

III бүлекнең 3.4.4 пунктчасының беренче абзацында «Оешмага чираттан тыш, беренче чиратта күчерелү хокукы» сүзләрен «Оешмага чираттан тыш, беренче чиратта өстенлекле рәвештә күчерелү хокукы» сүзләренә алмаштырырга;

I бүлекнең 1.8 пунктындагы икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен биналарда урнашкан муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текстлы мәгълүмат стендлары ярдәмендә. Татарстан

Республикасы дәүләт телләрендә мәгълүмат әлеге административ регламентның 1.1, 1.3, 2.3, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) муниципаль хезмәт турында белешмәләрне үз эченә ала»;

III бүлекнең 3.8 пунктын төшереп калдырырга;

II бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

II. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы | Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы | Муниципаль хезмәтне яисә таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Муниципаль хезмәтнең исеме | Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм алу | Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Төп гомуми белем бирү программалары - мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2013 елның 30 августындагы 1014 номерлы боерыгы |
| 2.2. Башкарма хакимият органы исеме | Муниципаль хезмәт «ТР Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ һәм әлеге административ регламентка 1 нче кушымтада күрсәтелгән мәгариф оешмалары тарафыннан күрсәтелә. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затлар булып «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ (алга таба - вәкаләтле хезмәткәр) хезмәткәрләре тора. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органнар Мөрәҗәгать итүчедән әлеге Административ регламентта каралган хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәсендә күрсәтелә торган хезмәтләрне, шул исәптән муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле һәм башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга мөрәҗәгать итү белән бәйле гамәлләрне, шул исәптән килештерүләрне гамәлгә ашыруны таләп итәргә хокуклы түгел. | «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.3Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып баланы мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмасына (балалар бакчасы) алу тора. | Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Төп гомуми белем бирү программалары - мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2013 елның 30 августындагы 1014 |

| | | |
|---|---|---|
| | | номерлы боерыгы |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып | Муниципаль хезмәт күрсәтү гамәлгә ашырыла:<br>- Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында гаризаны тутырган яисә «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесендә кәгазь чыганакта гариза биргән мизгелдән исәпкә кую өлешендә;<br>- Балаларны Оешмага күчерү өлешендә – Мөрәҗәгать итүче һәм Оешма арасында килешү төзелгән вакыттан алып. | |
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле һәм мәҗбүри булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелергә тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булган документларның тулы исемлеге мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны бирү тәртибе | 1. Мөрәҗәгать итүче баланы исәпкә кую өчен гариза тапшырганда кирәкле белешмәләр исемлеге:<br>- баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме;<br>- баланың туу датасы;<br>- туу турында таныклык мәгълүматлары;<br>- фактта яшәү урыны (адресы);<br>- әнисе, әтисе яисә законлы вәкилләрнең фамилиясе, исеме, атасының исеме, электрон почта адресы, контакт телефоны номеры;<br>- ата-ананың (законлы вәкилнең) шәхесен раслаучы документ мәгълүматлары;<br>- баланы мәгариф оешмасына күчерү буенча ташламаларның барлыгы турындагы белешмәләр;<br>- баланың сәламәтлеге буенча ихтыяҗы;<br>- ата-ана теләгән бер оешма;<br>- төркемдә тәрбия һәм укытуның ата-ана теләгән теле;<br>- баланы Оешмага алуның ата-ана теләгән датасы;<br>- теләгән оешмада урын булмаганда, башка балалар бакчасының тәкъдименә риза булу/риза булмау.<br>2. Баланы Оешмага җибәрү өчен кирәкле документлар исемлеге (Мөрәҗәгать итүче тарафыннан оешмага шәхсән мөрәҗәгать иткәндә бирелә):<br>- оешма җитәкчесе исеменә ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) язма гаризасы;<br>- билгеләнгән үрнәктәге медицина бәяләмәсе (сәламәтлек саклау учреждениеләре тарафыннан бирелә);<br>- баланың ата-анасының (законлы вәкилләренең) берсенең шәхесен раслый | «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Төп гомуми белем бирү программалары - мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2013 елның 30 августындагы 1014 номерлы боерыгы |

| | | |
|---|---|---|
| | торган документ;<br>- психолог-медицина-педагогика комиссиясе бәяләмәсе (баланы компенсацияләү һәм катнаш юнәлеше төркемнәргә керткәндә таләп ителә, психология-медицина-педагогика комиссиясе тарафыннан бирелә) | |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | Ташламаларны раслый торган документлар:<br>- күпбалалы гаиләләрдән булган балалар;<br>- Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарның балалары;<br>- инвалид балалар;<br>- ата-аналарның берсе булса да инвалид булган гаиләләр.<br>Документлар социаль яклауның территориаль органнары тарафыннан бирелә. | |
| 2.7. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Исәпкә кую өлешендә:<br>- баланың яше Оешмага кабул ителә торган балаларның максималь яшеннән арту.<br>Оешмага керү өлешендә:<br>- «Электрон балалар бакчасы» системасында баланы Оешмага җибәрү турында мәгълүмат булмау | |
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яисә кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Исәпкә кую өлешендә:<br>- бала туу турындагы таныклыкның күрсәткечләрен идентификацияләү процедурасына комачаулаучы дөрес булмаган (җитәрлек булмаган) белешмәләр бирү;<br>- баланың яше Оешмага кабул ителә торган балаларның максималь яшеннән арту;<br>- теләгән оешмада тәрбия һәм укытуның тәрбия бирү һәм укытуның ата-ана теләгән телгә туры килмәве.<br>Оешмага керү өлешендә:<br>- «Электрон балалар бакчасы» системасында баланы оешмага җибәрү турында мәгълүмат булмау;<br>- медицина ягыннан Оешмага баласның йөрүенә каршылыклар булу;<br>- ата-ананың (законлы вәкилләрнең) муниципаль хезмәт алудан баш тарту турында гаризасы | Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Төп гомуми белем бирү программалары - мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2013 елның 30 августындагы 1014 номерлы боерыгы |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яисә башка түләүне алу | Муниципаль хезмәт бушлай күрсәтелә | |

| | | |
|---|---|---|
| тәртибе, күләме һәм алу нигезләре | | |
| 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәткән өчен, мондый түләүнең күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп, түләүне алу тәртибе, күләме һәм аның алыну нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында, муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрне күрсәтү турында запрос биргәндә һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы | Шәхси кабул итүне көтү вакыты чиратта 15 минуттан да артык булырга тиеш түгел. Әгәр дә хезмәт пенсионерларга, инвалидларга бирелә икән, киләсе Мөрәҗәгать итүченең көтү (хезмәт күрсәтү) вакыты 30 минутка кадәр озайтылырга мөмкин.<br>Мөрәҗәгать иткән барлык затларны кабул итү эш көне тәмамланырга 1 сәгатьтән дә соңга калмыйча тәэмин ителергә тиеш | |
| 2.13. Муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәт һәм хезмәт күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең запросын теркәү срогы һәм тәртибе, шул исәптән электрон рәвештә | Мөрәҗәгать итүнең «ТР Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУнә шәхсән мөрәҗәгатен исәпкә кую турында гаризаны теркәү Мөрәҗәгать итүче Административ регламентның III бүлегендә каралган тәртиптә мөрәҗәгать иткән вакыттан 1 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла. Баланы Оешмага алу турында гаризаны теркәү Административ регламентның III бүлегендә каралган тәртиптә Мөрәҗәгать итүнең мөрәҗәгать | |

| | | |
|---|---|---|
| | иткән вакыттан алып 1 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла. | |
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга таләпләр | Мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен биналарда муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган муниципаль хезмәт турында мәгълүмат стендлары урнаштырыла. Бинаның алгы өлешенә мәгариф белән идарә итүнең муниципаль органы исеме турында мәгълүмат урнаштырыла. Мөрәҗәгать итүчеләргә документларны рәсмиләштерү мөмкинлеге булган урындыклар, өстәлләр белән җиһазландырылган урыннар бирелә. Бина санитария кагыйдәләре һәм нормалары нигезендә җиһазландырылырга тиеш. | «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июнендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.15. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык һәм сыйфат күрсәткечләре | - документларны кабул итү һәм карау срокларын үтәү;<br>- муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алу срогын үтәү;<br>- вазыйфаи затлар тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы булган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын бозуга прецедентлар (нигезле шикаятьләр) булу | «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июнендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.16. Электрон рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләре | Муниципаль хезмәтне электрон рәвештә күрсәтү Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (https://uslugi.tatar.ru) гамәлгә ашырыла | «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июнендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон |

Түбәндәге эчтәлекле VI бүлек белән тулыландырырга:

«VI. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү үзенчәлекләре

6.1. Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт алу өчен дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүнең күпфункцияле (алга таба – КФҮ) үзәгенә мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

6.2. КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү КФҮ регламенты нигезендә расланган билгеле тәртиптә гамәлгә ашырыла.

6.3. КФҮ тән муниципаль хезмәт алуга документлар алганда процедуралар әлеге Административ регламентның 3.4-3.7 пунктларында каралганча башкарыла. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәсе КФҮ кә юллана.»;

1нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

3нче кушымтаны төшереп калдырырга.

2. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУнә:

2.1. әлеге карарны муниципаль белем бирү оешмалары җитәкчеләренә һәм хезмәткәрләренә җиткерергә;

2.2. «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм алу» муниципаль хезмәтен кулланучы гражданнарга мәгълүмат җиткерүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Интернет мәгълүматый-телекоммуникация челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнашкан рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.А. Биккуловага йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров